РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы, ул. Пионерская, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге
Советы

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы, Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www. karmalinskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.09.2024ел № 21

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 20 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Кармалы авыл җирлеге Советы хәл итә:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 20 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге советы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«4.1) 2025 елда - 1,2 процент, 2026 елда - 1,2 процент, 2027 елда - 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата - 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексыныц 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән,

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган».

2 пунктның 1 пунктчасының 2 абзацында «мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игъланитәргә.
3. 2 пунктның 4.2 пунктчасы 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

«Совет Кармалинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан» ИНН 1630003122 ОГРН 1021602514471

А.Д. Кубышкин